Кинҗәгулов, О. "Татар театры җан рәхәте бирә" / О. Кинҗәгулов; [әңгәмәдәш] Р. Мөхәммәтова // Шәһри Чаллы. – 2022. – №90 (9 декабрь). – Б. 4.



# Олег Кинҗәгулов: «Татар театры җан рәхәте бирә»


С.Камалетдинов фотосы

Рузилә **Мөхәммәтова**

**Чаллы татар дәүләт драма театрының сәнгать җитәкчесе, режиссер Олег Кинҗәгулов әлеге театрда дүртенче сезонын эшли. Без Олег белән ул әлеге вазифага билгеләнгәч сөйләшкән идек (бу интервью газетаның 2020 елның 18 сентябрь санында дөнья күрде), монысы – икенче интервью.**

### Белешмә

Олег Кинҗәгулов 1989 елның 12 апрелендә Омск өлкәсендә туа.
Уфа дәүләт сәнгать институтында һәм Казан дәүләт мәдәният институтында белем ала. Туймазы театрында актер булып эшли. Чаллы татар дәүләт драма театрында һәм Казанның Г.Камал театрында чакырылган режиссер буларак спектакльләр куя. 2020 елда Чаллы татар дәүләт драма театрының сәнгать җитәкчесе итеп билгеләнә.

Бүген Аяз Гыйләҗев исемендәге Чаллы театрының 30 еллык тарихы бар. 2020 елда труппа зур бинага күчте. **Олег Кинҗәгулов** яңа шартларда ирешкән уңышлары һәм хыяллары турында сөйләде.

## «Театр – мәңгелек!»

**– Олег, Чаллыга ник килдем, дип үкенеп, Казанга кайтып китәсе килгән чаклар буламы?**

– Бер дә булмады. Киресенчә, үҗәтләнеп эшлим. Беләсеңме, быел мин – «Идел-йорт» халык театрлары фестиваленең жюри рәисе. Хәзер финалга чыккан 12 спектакльне карыйбыз. Күбесе – Кама аръягы төбәкләренең халык театрлары куйган сәхнә әсәрләре. Шунысы куандыра – алар иҗади яктан көчлерәк тоелды. Бәлки профессиональ театрларның йогынтысы булгандыр – бүген һәвәскәр театрларның үсеше күренә. Җавабым шул: беркая да китәсем килми – Кама аръягында театр сәнгатен күтәрергә кирәк, чөнки монда иҗади мөмкинлекләр зур.

**– Олег, хәзер театрларда тамашачы артты, диләр. Сездә дә шулаймы?**

– Әйе. Бәлки бу – бүгенге вәзгыятьтә кинотеатрларда яңа фильмнар бик аз булуына да бәйледер. Без хәзер: «Кина нет, театр вечен», – дип көлешәбез. Театр – мәңгелек!

**– Чаллы театрында эшләү дәверендә нинди уңышларга ирештең һәм алга таба ниләр турында хыялланасың?**

– Мәдәният министрлыгы безгә – театр җитәкчеләренә – базар шартларында үз продукцияңне танытырга өйрәтә торган маркетинг курсларында укырга мөмкинлек бирде. «Режиссерга менеджмент кирәкме?» – дип сорыйлар. Кирәк! Бервакыт дәрестә укытучы: «Театр өлкәсендә нинди хыялыгыз бар?» – дип сорады. «Көн саен тулы залларга спектакльләр күрсәтү», – дидем. «Елына – миллион кеше», – дим. Бәлки бу хыял – утопиядер. Ләкин шушы 2,5 елда театрны ничектер таныта алдык кебек. Яңа, яшь тамашачы килде. Репертуарыбыз жанрлар ягыннан баеды. Актерлар заманча эшләргә өйрәнде.

## «Яңа спектакльләр яңа тамашачы китерде»

**– Бернинди дә проблема юкмы?**

– Театрда эш урыннары җитми. Бинабыз зур, күп функцияле. Ике залда – зур һәм кече сәхнәләрдә – бер үк вакытта уйныйбыз. Әмма элеккеге кечкенә бинадагы штатлар белән эшлибез. 29 актерның күбесе – өлкән яшьтә. Миңа артистлар да, техник хезмәткәрләр дә җитми. Мондый бина өчен кимендә 40 актер кирәк. Башка театрларның бюджеттан тыш штаты була. Ә мин әлегә аны берничек тә булдыра алмыйм...

**– Булган акчаңа спектакль чыгарасың...**

– Әйе, шуңа китә.

**– Театрга бүтән режиссерлар чакырмавың үзең эшлисе килүдәнме, әллә түләргә акчаң юкмы?**

– Әлбәттә, акча җитмәүдән инде.

**– Ә өстәмә штатлар булса, «киләм» дип торган талантлы артистлар бармы?**

– Шунысы сөендерә – Казан һәм Алабугадан безгә эшләргә килергә теләүче яшьләр бар.

**– Кайда яшәрләр? Сездә бит яшьләр өчен торак проблемасы кискен тора.**

– Безнең карамакта хәзер ике фатир: берсендә – кызлар, икенчесендә егетләр яши. Чаллы шәһәре Башкарма комитеты безнең хәлгә керә – алар ярдәм итәргә әзер.

**– Сиңа ышанып яңа театр төзергә килгән кешеләр әле дә эшлиме? Әллә акча юклыгын аңлап яки башка сәбәпләр белән китеп тә бардымы?**

– Барысы да эшли. Башка театрлардан да: «Сездә эшләргә телим», – дип килүчеләр булды.

**– Труппа синнән канәгатьме? Әллә артыңнан зарланалармы икән?**

– Труппа белән эш мөнәсәбәтләре бик җылы, дип әйтәсем килә. Берберебезгә ышанмасак, сезонга җиде премьера чыгара алмаган булыр идек, *мөгаен*. Коллегаларыма рәхмәт әйтәсем килә.

**– Ә тамашачы арасында сине «театрны боздың» дип сүгеп китүчеләр юкмы?**

– Нишләп булмасын?! Биткә бәреп әйтмәсәләр дә, сизәм инде. Бөтенесенә дә ошап бетә алмыйсың бит. Әмма бүген репертуарга күз салсаң, төрле тамашачының зәвыгына туры килә торган спектакльләр бар.

**– Яңалармы?**

– Иске спектакльләр репертуардан акрынлап төшеп кала. Элеккеге бинада өчпочмаклы кечкенә сәхнә иде. Спектакльләр дә шуңа көйләнгән. Хәзер алар зур сәхнәдә югалып калды.

**– Ә бер сезонга җиде премьера кирәк идеме?**

– Кирәк инде, нишләп кирәкмәсен?! Иске репертуар белән яңа бинага күчүне күздә тотмадым...

**– Чаллыга күчкәндә иске киемнәреңне калдырып киттеңмени? Казанда кигән джемперларыңны алып килгәнсеңдер бит?**

– Әйе.

**– Нишләп яңа театрга иске спектакльләрне алмыйсыз, дим.**

– О-о-о, метафораң көчле булды. Минем киемнәр бик тузмаган әле, хәзер дә рәхәтләнеп киеп йөрим. Ә театрда проблема җитдирәк иде. Мәсәлән, декорацияләре искергән спектакльне рәткә китерүгә шулкадәр зур көч түгелә, ул яңа спектакль чыгаруга тиң була. Шуңа күрә яхшылап уйладык та, искене яраклаштыру белән шөгыльләнмәскә булдык. Яңа спектакльләр исә театрга яңа тамашачы китерде.

**– Көн саен эшкә киләсеңме? Хәер, өйдә нишлисең инде... Син өйләнмәдең бит әле, әйеме?**

– Хатын алып кайтырлык өем дә юк бит әле. Шагыйрь әйтмешли, хатыным – поэзия.

## «Әдәбиятны таныту – әһәмиятле миссия»

**– Олег, синең күзаллавыңда милли театр нәрсә ул?**

– Милли театр ул – классик әсәрләрнең гыйффәтле чишелеше. Проблеманың актуальлеге, чөнки татар сәхнәсендә, һичшиксез, проблема булуы шарт. Тел, сүзнең моңы булырга тиеш. Әйтик, актер төп рольдә уйный, ә телендә моң юк. Аллага шөкер, өлкән артистларыбыз яшьләргә киңәшләр бирә, кайсы сүзгә ничек басым ясарга кирәген аңлата. Милли театрны тоярга кирәк.

Без Фәтхи Бурнашның «Яшь йөрәкләр» музыкаль комедиясен сәхнәләштердек. Чаллы тамашачысы мондый самими спектакльләргә сусаган иде. Артистлар да ләззәтләнеп, тәмен белеп уйный. Мин театрда сезон саен, йә ике сезонга бер тапкыр татар классикасы куелырга тиеш, дип уйлыйм. Беләсеңме, Чаллы халкы Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл»ен сәхнәләштерүне сорый.

**– Татар классик язучыларының сәхнәгә куела торган унлап кына драма әсәре бар бугай...**

– Булса соң, димәк, минем 20 елга эш планым бар, дигән сүз. Безнең театрда бер очрашу булган иде. Татар теле укытучылары килде, балалар укымый, дип зарланалар. Татар театры нигә моның белән шөгыльләнмәскә тиеш әле, дигән уй туды... Мәсәлән, бөек шагыйрьләрнең шигырьләрен җыелып укырга мөмкин. Без әдәбиятны танытуны бик әһәмиятле миссия, дип саныйбыз. Шундый зур бинабыз бар икән, җаваплылык та арта – белем бирү-агарту эшчәнлеген киңәйтергә тиешбез.

**– Чаллыдагы «Мастеровые» рус драма театры сезгә көндәшме?**

– Юк, алар безгә комачауламый. Киресенчә, аларның булуы безгә үсәргә булыша. «Мастеровые»ның яңа бинасы ачылганга да 2 ай узды, һәм шәһәр халкы чагыштыра башлады. Рус театры – рус театры инде ул, ә татар театры – татар театры. Иҗади алымнарыбыз да, идея дә башка. Безнең театрга килү тамашачыларга җан рәхәте бирә. Элек татар театры нык калыша иде, бүген инде без бер дәрәҗәдә.

ИТ ИНТЕРТАТ
БУ ХАКТА ТУЛЫРАК
INTERTAT.TATAR САЙТЫНДА